| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СУГУШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «СУГЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

2025 елның 2 октябре №14

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 24 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 24 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк»сүзләренә алмаштырырга;

2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктча өстәргә:

«4.1) мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Татарстан Республикасы башкарма органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрен башкару өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәтне мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә күрсәткәндә, күрсәтелгән максатларда мондый затның яисә аның законлы вәкиленең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми;».

2.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк ур., 27 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниипаль районы
« Сугышлы авыл җирлеге»
муниипаль берәмлеге башлыгы А.П.Зыятдинова